СОВЕТ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23.09.2021 п.г.т. Аксубаево № 74

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларын (иҗтимагый фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 24 августындагы 157 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Җирле үзидарә органның хокукый актларын Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларын (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 24 августындагы 157 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 12 статьясындагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирлекләрнең генераль планнары, шәһәр округларының генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына, шәһәр округларының генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча иҗтимагый фикер алышулары яисә ачык тыңлаулар муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында уздырыла, территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул итүгә бәйле рәвештә, җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш, иҗтимагый фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.».

1.2. 1 нче кушымтаның 4 статьясындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ачык тыңлаулар халык, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы, муниципаль берәмлек башлыгы яки җирле администрация башлыгы инициативасы буенча үткәрелә.»

1.3. 1 нче кушымтаның 5 статьясындагы 1пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халык яисә Совет инициативасы буенча үткәрелә торган ачык тыңлаулар Совет карары белән билгеләнә.

Контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле администрация башлыгы яисә башлыгы инициативасы буенча үткәрелә торган ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә.

Ачык тыңлаулар Россия Федерациясе законнары белән җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча үткәрелә.»

1.4. Карарны түбәндәге эчтәлекле 2 пункты белән тулыландырырга:

«2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Аксубай муниципаль районында халык тыңлаулар үткәрү буенча нигезләмә турында» 2012 елның 28 июнендәге 106 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

1.5. Карарның 2 һәм 3 пунктларын 3 һәм 4 пунктлары дип санарга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Аксубай муниципаль районы сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Аксубай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,

Совет Рәисе К. К. Гыйлманов